РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БОЛЬШЕЯКИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

422524, Зеленодольский район,
село Большие Яки,
улица Школьная, дом 1
*тел./факс 6-60-44*

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯШЕЛ ҮЗӘН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ОЛЫ ЖӘКЕ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

422524, Яшел Үзән районы,
Олы Яке авылы,
Мәктәп урам, 1 йорт
*тел./факс 6-60-44*

# ПОСТАНОВЛЕНИЕ
# КАРАР

**16 февраль 2021 ел.** **№6**

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Олы Җәке авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә агач һәм куаклар кисүгә, кронлаштыруга һәм утыртуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең 2020 елның 18 маендагы 15 номерлы Олы Җәке авыл җирлеге башкарма комитеты карары белән расланган административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Олы Җәке авыл җирлеге башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Олы Җәке авыл җирлеге Башкарма комитетының 2020 елның 18 маендагы 15 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Олы Җәке авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә агач һәм куаклар кисүгә, кронлаштыруга яисә утыртуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына (алга таба – Административ регламент) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 1.2 Пункт. Административ регламентны яңа редакциядә бәян итәргә:

«1.2. Муниципаль хезмәт алучылар: физик һәм юридик затлар (алга таба-мөрәҗәгать итүче).

Мөрәҗәгать итүченең Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычлары булмау, авария хәлләренә бәйле очраклардан тыш, бу хезмәт күрсәтүне алу шарты булып тора.»;

1.2 «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» дигән 2 нче графаның 2.6 пунктына түбәндәге эчтәлекле 2 пунктча өстәргә:

2) мөрәҗәгать итүченең Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычлары булмавы (булуы) турында белешмә, авария хәлләренә бәйле очраклардан тыш.».

1.3 «Стандартка карата таләпләрнең эчтәлеге» дигән 2 нче графаның 2.8 пунктына түбәндәге эчтәлекле 5 пунктча өстәргә:

5) мөрәҗәгать итүченең Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычлары (авария хәлләренә бәйле очраклардан тыш) булуы.».

1.4 3.4.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4.1. Бүлек белгече электрон формада ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша бирү турында запрос җибәрә:

Күчемсез милеккә һәм аның белән алыш-бирешләргә хокукларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә (күчемсез милек объектына теркәлгән хокуклар турында һәркем өчен мөмкин булган мәгълүматлар).

Мөрәҗәгать итүченең Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычлары булмавы (булуы) турында белешмә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза кергән көннән алып бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: җибәрелгән запрос.»

1.5 Агач һәм куакларны кисүгә, кронлаштыруга яисә утыртуга рөхсәт бирү турында гариза (Административ регламентның 1 нче кушымтасы) түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Шәхси мәгълүматлар турында»гы 27.07.2006 ел, №152-ФЗ Федераль законның 9 статьясы нигезендә, шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык бирәм.»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга, Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районы сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә, шулай ук Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы Олы Җәке авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында: Олы Яке авылы, Мәктәп урамы, 1 (авыл җирлеге администрациясе бинасы), Мәктәп урамы, 1 а( Олы Җәке КФҮ бинасы), Каратмән авылы, Клубная урамы, 23 (авыл клубы бинасы), Уразлы авылы, Подгорная ур., 138п.

3.Әлеге карар үтәлешен контрольгә алуны үземдә калдырам.

**Олы Җәке авыл жирлеге башлыгы** **Ф.А.Фәйзуллина**